ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НОРМА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» декабрь 2022 ел № 86

**Мәгълүмат кулланучыга**
**аның соравы буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Башкарма комитет эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

2022 елның 14 июлендәге № 270-ФЗ номерлы «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында»гы Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында»гы Федераль законның 10 статьясы, 2022 елның 28 ноябрендәге №02-01-22-2022 номерлы прокуратура хаты нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге башкарма комитеты **карар бирә:**

1. 2013 елның 24 июнендәге № 11 номерлы (17.02.2015 № 3, 04.09.2015 № 14/1 ред. үзгәрешләр белән) Мәгълүмат кулланучыга аның соравы буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Башкарма комитет эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктының 1 пунктындагы «күрсәтелгән оешмалар» сүзләрен «Башкарма комитет һәм күрсәтелгән оешмалар» сүзе белән алмаштырырга;

1.2. 1.2 пунктны түбәндәге эчтәлекле 4 пунктка өстәргә:

“4) Башкарма комитет яки аның карамагындагы оешма эшчәнлеге турында мәгълүматны үз эченә алган «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге сайт – рәсми сайт”;

1.3. 2.1 пунктына «, шулай ук гомуми файдаланудагы элемтә челтәрләре буенча» сүзләренә өстәргә;

1.4. 2.3 пунктының 1 абзацында «Татарстан Республикасы» сүзләрен «Россия Федерациясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.5 пунктының беренче абзацында «2.10 пункт» сүзләрен «2.11 пункт» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 2.5 пунктның 2 абзацында «министрлыклар» сүзен «Башкарма комитет» сүзе белән алыштырырга;

1.7. 2.6 һәм 2.7 пунктларын төшереп калдырырга;

1.8. 2.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Мәгълүмат мондый информацияне бирү тәртибен регламентлаучы законнар нигезендә түләүсез рәвештә бирелә.»;

1.9. 2.9 пунктының 1 абзацында «2.8 пункт» сүзләрен «2.3 пункт» сүзләренә алмаштырырга;

1.10. 2.9 пунктының 3 абзацын төшереп калдырырга;

1.11. 2.11 пунктның 7 абзацында «, анын территориаль органнарын» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.12. 2.11 пунктның 8 абзацында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сүзләрен «рәсми сайтта» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар рәсми бастырылганнан соң үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Норма авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе З.Н. Низамова